**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

09.11.2023 1317-п

«Петровский заводы» ҖЧҖ №№1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зоналарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы нигезендә, 2023 елның 16 мартындагы җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ 013092 ВР серияле лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2022 елның 29 декабрендәге № 16.07.01.000.Т.000029.12.22 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авылында урнашкан «Петровский завод» ҖЧҖ №№ 1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зоналары проекты нигезендә боерык бирәм:

1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләрене чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-

02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авылында урнашкан «Петровский завод» ҖЧҖ №№ 1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрен, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә территориядән хуҗалыкта файдалану режимын билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Петровский завод» ҖЧҖ;

- «Роскадастр» иҗтимагый-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына – санитар саклык зоналарын (алга таба – ССЗ) билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетына.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрергә тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авылында урнашкан «Петровский завод» ҖЧҖ №№ 1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зонасы чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
09.11.2023 ел, № 1317-п
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авылында урнашкан «Петровский завод» ҖЧҖ №№ 1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләре

Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү, аларны барлау һәм чыгару максатларында кулланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты суларын геологик өйрәнү максатларында җир асты суларын алу өчен кулланыла торган гамәлдәге су алу участогы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авылының көнбатыш читендә, Завод урамындагы 35 нче йорт адресы буенча урнашкан.

Су корылмасы файдаланыла торган биш скважинадан тора. №№ 1, 2 скважиналар арасындагы ераклык – 70 м, №№ 2, 3 скважиналар арасындагы ераклык – 56 м, №№ 3, 4 скважиналар арасындагы ераклык – 120 м, №№ 4,5 скважиналар арасындагы ераклык – 180 м.

Скважинаның географик координатлары:

№ 1 - 55°19′2,92″, 52°29′30,36″;

№ 2 - 55°19′1,37″, 52°29′27,59″;

№ 3 - 55°19′0,18″, 52°29′29,97″;

№ 4 - 55°18′57,61″, 52°29′35,18″;

№ 5 - 55°18′55,33″, 52°29′25,85″ (WGS-84 координаталар системасы).

Санитар саклык зонасының беренче поясы астында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:36:190102:558.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сuүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

<u>Санитар саклык зонасының I поясы</u>

№ 1 скважина өчен ССЗ беренче поясы чиге булган койма чикләрендә билгеләнә:

- 4,96 м – көнчыгышка, көньяк-көнчыгыш юнәлештә,
- 5,08 м – төньяк-төньяк-көнчыгыш юнәлештә,
-4,52 м – көнбатыш-төньяк-көнбатыш юнәлештә,
- 4,98 м – көньяк-көньяк-көнбатыш юнәлештә;

№2 скважина өчен:

-3,19 м – көнчыгыш-көньяк-көнчыгыш юнәлештә,
- 3,66 м – төньяк-төньяк-көнчыгыш юнәлештә,

- 3,11 м – көнбатышка-төньяк-көнбатыш юнәлештә,
- 2,9 м – көньяк-көньяк-көнбатыш юнәлештә;

№3 скважина өчен:

-3,87 м – көнчыгыш-көньяк-көнчыгыш юнәлештә,
-3,17 м – төньяк-төньяк-көнчыгыш юнәлештә,
- 2,46 м – көнбатышка-төньяк-көнбатыш юнәлештә,
- 3,62 м көньяк-көньяк-көнбатыш юнәлештә;

№4 скважина өчен:

- көньяк-көнчыгыш юнәлештә 5 м,
- төньяк-көнчыгыш юнәлештә 5 м,
- төньяк-көнбатыш юнәлештә 4 м,
- көньяк-көнбатыш юнәлештә 5 м;

№5 скважина өчен: төньяк, көнчыгыш, көньяк, көнбатыш юнәлешләрдә 6 м.

Санитар саклык зонасының II поясы

ССЗ икенче поясы чиге кырый скважиналардан 72 м радиус белән билгеләнә (№1 скважинадан төньяк юнәлештә, №2 скважинадан төньяк-көнбатыш юнәлештә, №4 скважинадан көнчыгыш юнәлештә, №5 скважинадан көньяк юнәлештә);

Санитар саклык зонасының III поясы

Санитар саклык зонасының өченче поясы чиге кырый скважиналардан 420 метрлы радиус белән билгеләнә. ССЗ өченче поясы чиге көнбатыш юнәлештә 200 м аралыкта урнашкан, Игәнә елгасы үзәнлеге белән чикләнгән.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының
09.11.2023 ел, № 1317-п
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авылында урнашкан «Петровский завод» ҖЧҖ №№ 1, 2, 3, 4, 5 су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрне хуҗалык өчен файдалану режимы

1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үткәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар-саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналар бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик яклanган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

## 3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.2. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.).